ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

**№ 375** **25.08.2026 ел**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Түләүле хезмәтләр бәясен раслау турында» 2026 елның 22 июнендәге 247 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2023 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсен гамәлгә ашыру, шулай ук балаларны, яшүсмерләрне һәм өлкәннәрне физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итү һәм аларда сәламәт яшәү рәвеше формалашу, физик, интеллектуаль шулай ук әхлакый сыйфатлар үсеше, сәләтләренә карап спортта уңышларга ирешү, ял итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 22 июнендәге 247 номерлы карарына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Боз спорт сарае «Спорт мәктәбенең» өстәмә белем бирү МБУ директоры Морозов Евгений Геннадьевичка әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э. Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 25 августындагы
375 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
"Боз спорт сарае "Спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү
муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәт күрсәтүләр эшчәнлегенең
төп төрләренә караган бәяләр прейскуранты

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Категория | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | Бозда шуу (тимераякларны прокатка бирмичә | барлык категорияләр (1 сәгать) | 200-00 |
| 2 | Бозда шуу (тимераяк прокаты белән) | барлык категорияләр (1 сәгать) | 250-00 |
| 3 | Боз аренасын бирү | барлык категорияләр (1 сәгать) | 6250-00 |
| 4 | Командаларның күнекмә җыеннарын уздыру өчен боз аренасы бирү | барлык категорияләр (1 сәгать | 5000-00 |
| 5 | Хоккей сөючеләр өчен дәресләр | бер дәрес (өлкәннәр өчен) | 280-00 |
| | | бер дәрес (мәктәп укучылары, студентлар өчен) | 140-00 |
| | | 1 айга абонемент (атнага 2 тапкыр килүчеләр өчен) барлык категорияләр | 1680-00 |
| 6 | Шейпинг, фитнес, көнчыгыш биюләре, спорт биюләре, степ-аэробикасы белән шөгыльләнү | бер дәрес (барлык категорияләр) | 250-00 |
| | | 1 айга абонемент (8 дәрескә кадәр) | 1000-00 |
| | | 1 айга абонемент (12 дәрескә кадәр) | 1200-00 |
| 7 | Тренажер залында дәрес | өлкәннәр өчен бер дәрес (1 сәгать) | 170-00 |
| | | мәктәп укучылары, студентлар өчен бер дәрес (1 сәгать) | 130-00 |
| | | 1 айга абонемент (8 дәрескә кадәр) | 1206-00 |
| | | 1 айга абонемент (12 дәрескә кадәр) | 1690-00 |
| 8 | Күргәзмәләр, семинарлар, корпоратив һәм тантаналы чаралар уздыру өчен 66,8 кв. м мәйданлы VIP зал бирү | барлык категорияләр (1 сәгать) | 1300-00 |
| 9 | Боз аренасында реклама урыны (1 кв м) бирү | барлык категорияләр (ай) | 1700-00 |
| 10 | Кунакханә хезмәтләре | барлык категорияләр (тәүлек) | 800-00 |
| | Спорт ярышларында һәм чараларында катнашучылар өчен кунакханә хезмәтләре күрсәтү | барлык категорияләр (тәүлек) | 700-00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | Өстәл теннисы | барлык категорияләр (1 сәгать) | 300-00 |
| 12 | Сауна хезмәтләре күрсәтү (5 кешедән артык түгел) | барлык категорияләр (1 сәгать) | 1750-00 |
| 13 | Бильярд залы хезмәтләре | барлык категорияләр (1 сәгать) | 600-00 |
| 14 | Хореография залын бирү (1 кеше өчен) | барлык категорияләр (1 сәгать) | 450-00 |
| 15 | Хореография залын бирү (5тән 15 кешегә кадәр төркем өчен) | барлык категорияләр (1 сәгать) | 1250-00 |
| 16 | Тренажер залы бирү (5тән 15 кешегә кадәр төркем өчен) | барлык категорияләр (1 сәгать) | 1300-00 |
| 17 | Тренер белән шәхси дәресләр | барлык категорияләр (1 сәгать) | 600,00 |

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 22 июнендәге
247 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
"Боз спорт сарае "Спорт мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет
учреждениесендә эшчәнлекнең төп төрләренә керми торган
түләүле хезмәтләр күрсәтү бәяләре прейскуранты

| № п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Категория | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | Fiat Ducato автобусын бирү | барлык категорияләр (1 сәгать) | 2520-00 |
| 2 | Hyundai Universe автобусын бирү | барлык категорияләр (1 сәгать) | 4385-00 |
| 3 | Yutong ZK 694H автобусын бирү | барлык категорияләр (1 сәгать) | 3400,00 |
| 4 | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алып Fiat Ducato автобусын бирү | барлык категорияләр (1 км өчен) | 70 |
| 5[1] | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында эшләүче бюджет учреждениеләренә Fiat Ducato автобусын хезмәт максатларында сәяхәт итү өчен бирү | 1 км өчен | 37 |
| 6 | Hyundai Universe автобусын бирү | 1 км өчен | 100 |
| 7[2] | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында эшләүче бюджет учреждениеләренә Hyundai автоiverse автобусын хезмәт максатларында йөрү өчен бирү | 1 км өчен | 54 |
| 8 | Yutong ZK 694H автобусын бирү | 1 км өчен | 90 |
| 9[3] | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында эшләүче бюджет учреждениеләренә хезмәт максатларында йөрү өчен Yutong ZK 694H автобусын бирү | 1 км өчен | 46 |

Искәрмә: бюджет учреждениеләре өчен сәфәрләр оештырганда акчалар максатчан билгеләнеше буенча тулы күләмдә күчерелә һәм бары тик ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм учреждениенең транспорт чараларын карап тоту өчен генә файдаланылырга мөмкин.

---

[1] "Боз спорт сарае "Спорт мәктәбе"нең өстәмә белем бирү учреждениесендә ягулык лимитлары чикләнгән очракта, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджет учреждениеләренә хезмәт максатларында бару өчен Fiat Ducato автобусы заказчы автобуска ягулык салганда 1 км га 27 сум исәбеннән бирелә.

[2] "Боз спорт сарае "Спорт мәктәбе"нең өстәмә белем бирү учреждениесендә ягулык лимитлары чикләнгән очракта, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджет учреждениеләренә Hyundai Universe автобусын хезмәт максатларында бару өчен заказчы автобуска ягулык салганда 1 км га 30 сум исәбеннән бирелә.

[3] "Боз спорт сарае "Спорт мәктәбе"нең өстәмә белем бирү учреждениесендә ягулык лимитлары чикләнгән очракта, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының бюджет учреждениеләренә Yutong ZK 694H автобусы заказчы автобуска ягулык салганда 1 км га 26 сум исәбеннән бирелә.